РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
СТАРОСТУДЕНЕЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СУЫКСУ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» ноябрь 2016 ел № 22-2

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Иске Суыксу авыл җирлеге Советының 2016 елның
11 октябрендәге 21-1 номерлы «Җир салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында»

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2016 елның 11 октябрендәге 21-1 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Салым ставкалары» 2 статьяда 4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«4) оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,3 проценты;»

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан һәм рәсми игълан ителгән көненнән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, җирлектә махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән үз көченә керә.

ТР Буа муниципаль районы Иске Суыксу
авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Заһидуллина